Государственное бюджетное общеобразовательное учреждение Самарской области

средняя общеобразовательная школа с.Камышла муниципального района Камышлинский

Самарской области

Проверено
Зам. Директор по УВР

__________В.С.Михайлова

«30» августа 2022

Утверждаю
Директор ГБОУ СОШ с.Камышла
Приказ № 215-од
__________Каюмова А.Х
«31» августа 2022

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**

Предмет (курс) кружка «Школьный татарский театр «Тамчылар»

Класс 7

Количество часов по учебному плану 34 часа в год 1 час в неделю.

C=RU, OU=Директор, O=ГБОУ СОШ с. Камышла, CN=Айсылу Халиуловна Каюмова, E=kamyshl_sch_kmsh@samara.edu.ru
00b7cb52965f43019a
2022-11-17 15:58:01

Рассмотрена на заседании МО родного и английского языков

Протокол №_1_____ от «__29___»_____августа__________ 2022 г.

Председатель МО Хайретдинова Г.Ш._______________

Рабочая программа кружка «Школьный татарский театр «Тамчылар» разработана в соответствии с:

- Федеральным Законом от 29.12.2012 № 273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»,

- Федеральным государственным образовательным стандартом начального общего образования, утвержденным приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 31 05.2021г. № 286

- Федеральным государственным образовательным стандартом основного общего образования, утвержденным приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 31.05.2021 № 287,

- Федеральным государственным образовательным стандартом среднего общего образования, утвержденного приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 17.05.2012 № 413,

- Порядком организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам - образовательным программам начального общего, основного общего и среднего общего образования, утвержденным приказом Министерства просвещения Российской Федерации от 22.03.2021 № 115,

- Постановлениями Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 28.09.2020 № 28 «Об утверждении санитарных правил СП 2.4. 3648-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи», от 28.01.2021 № 2 «Об утверждении санитарных правил и норм СанПиН 1.2.3685-21 «Гигиенические нормативы и требования к обеспечению безопасности и (или) безвредности для человека факторов среды обитания»,

- Уставом ГБОУ СОШ с. Камышла

**“Тамчылар” театр түгәрәге программасы**

7 нче сыйныфлар өчен, 34 сәгать

**Аңлатма язуы**

Балаларның акыл һәм хыялын, зәвыгын, сөйләм культурасын, иҗади хезмәткә омтылышын тәрбияләү мәктәптә укытуның төп максатлары булып тора.

Бу максатларны тормышка ашыруда без сүз сәнгатенең, әдәбиятның матур үрнәкләренә мөрәҗәгать итәбез. Сәнгать әсәрләренең мәгънәсенә төшенү, гүзәллек, зәвык хисен үзләштерү бала өчен аерым сүздән башлана. Әдәбият дәресләрендә, дәрестән тыш чараларда бала сүзнең төсмерләрен, аһәңен, төгәллеген аңларга өйрәнә. Авазларны ишетмичә көйне аңлап булмаган кебек, сүзне тоемлау сәнгатеннән мәхрүм бала әсәрнең кыйммәтен танып белмәячәк, сәнгать әсәреннән эстетик ләззәт алмаячак. Аның өчен әдипнең сүзе күңел кылларына кагылып, инануга әверелмичә, мавыктыргыч сюжет булып кына калачак. Әдәби әсәрнең, сәнгатьле сүзнең тәэсир көче укыганны, сөйләгәнне күзаллаудан соң, яңа фикергә килү белән бәяләнә. Бер фикер икенчесен тудыра, бер образ хәтердә яки хыялда яңа образга үсә.

Теләсә нинди тезмә яки чәчмә әдәби әсәрне күңелдән ятлап, сәхнәдән тамашачыларга яисә дәрестә сөйләгәндә, ул сәнгать әсәре булып китә. Ни дәрәҗәдә сәнгатьчә булуына килгәндә, анысы сөйләүченең сәләтенә, осталыгына тапкырлыгына, тырышлыгына бәйләнгән була. Сәнгать әсәренең төп фикере сөйләүченең тел төбенә яшерелгән була. Контексттагы төп мәгънәне (тел төбен) аңлавыбыз сөйләүченең әсәрдәге хис-тойгыларны күңелебезгә үтеп керерлек итеп сөйли алуына бәйле.

Безнең татар сәнгате тарихында искиткеч дан-шөһрәткә ия булган Х.Әбҗәлилов, Ф.Ильская, Г.Шамуков, А.Арсланов, А.Хәйруллина, И.Әхмәтҗанов кебек сүз остазларыбыз бар. Балалар, аралашканда, чыгыш ясаганда, әнә шул остазларның сүз сәнгатенә мөнәсәбәтен күз алдында тотарга, аларның сәнгате дәрәҗәсенә омтылырга тиеш.

Сөйләм, аралашу осталыгы һәрбер һөнәр вәкиле өчен мөһим. Кызганычка каршы, хәзерге вакытта еш кына хаталы сөйләм, басым кую кагыйдәләре һәм авазлар орфоэпиясе бозылышы белән очрашырга туры килә. Телне, сөйләм төзү кагыйдәләрен, дөрес әйтелешне киңрәк өйрәтү сорала. Театр түгәрәге югарыда күрсәтелгән белем һәм күнекмәләрне камилләштерергә тиеш.

Театр түгәрәге шөгыльләрендә сөйләм осталыгын үстерү максатында түбәндәге күнегүләрне үткәрү карала.

1. Сүз басымын кую.
2. Сулыш күнегүләре.
3. Тартык һәм сузык авазларны дөрес әйтү күнегүләре.
4. Тавыш һәм дикция күнегүләре.
5. Текстның эчке мәгънәсен ачыклау.
6. Мәгънәви басым кагыйдәләре.
7. Сөйләм тизлеге.
8. Сөйләм ритмы һәм аһәңе.

Театр түгәрәге шөгыльләрендә сәнгатьле сөйләм осталыгына өйрәтү сәнгать осталары үрнәгендә, әдәби әсәрләр нигезендә һәм практик күнегүләр белән ныгытылып алып барыла.

Театр түгәрәге программасы 34 сәгатькә (атнага 1 сәгать исәбеннән) төзелде.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: театр татар сөйләменә өйрәнү өчен укучыларга коммуникатив мотивация, уңайлы шартлар булдыра.

Театр сәнгате әсәрләрендә халыкның рухи тәҗрибәсе, гореф-гадәтләре, әхлак нормалары. Менә шундый гадәтләрне өйрәнү, белү, күңел белән кабул итү укучы балаларда гуманлы мөнәсәбәтләр тәҗрибәсен тудыра, яңа гадәтләрнең, яңа әхлак нормаларының асылын аңларга, аларны чагыштырып-үлчәп карарга мөмкинлек бирә.Үзара бергәләп кичерелгән шатлыклар, бергәләп кичерелгән борчулар, бергәләп табылган уңышлар коллективны рухи яктан берләштерә, үзара ярдәм итешү, бер-берең өчен борчылу, бер-берең турында кайгырту кебек гуманлы хисләр тәрбияли.

**Театр түгәрәгенең максаты һәм бурычлары.**

1. Укучыларны чыгыш ясау һәм аралашу осталыгына өйрәтү.
2. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү (дикция, сулыш белән идарә итү, сөйләм тавышы кую, орфоэпия өстендә эшләү).
3. Укучыларның акыл һәм хыялын, зәвыгын, сөйләм культурасын, иҗади хезмәткә омтылышын үстерү.
4. Укучыга үзенең сөйләм осталыгын, талантын сынап карарга шартлар тудыру.
5. Татар милли театр сәнгате белән кызыксынуны үстерү.
6. Театр әсәрләренә таянып күркәм әхлакый сыйфатлар тәрбияләү

**Тематик планлаштыру**

| № | Уку материалының темасы | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Кереш шөгыль. Сөйләмдә уңышларым һәм җитешсезлекләрем. | 1 |
| 2 | Аралашу кагыйдәләре. | 1 |
| 3 | Татар сүз сәнгатенең күренекле вәкилләре. | 1 |
| 4 | Г. Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театры. Театрга экскурсия, спектакль карау. | 1 |
| 5, 6 | Чыгыш ясаганда, аралашканда кешенең гәүдәсен тотышы һәм мимикасының роле. | 2 |
| 7 | Хис-кичерешләрне белдерү. | 1 |
| 8 | Сулыш күнегүләре. | 1 |
| 9 | Сөйләм һәм яңгырау аппаратын күнектерү. | 1 |
| 10 | Сузык авазлар орфоэпиясе. | 1 |
| 11 | Тартык авазлар орфоэпиясе. | 1 |
| 12,13 | Басым һәм аның төрләре. | 2 |
| 14 | Мәгънәви паузалар. | 1 |
| 15 | Сөйләм тизлеге. | 1 |
| 16 | Сөйләмнең интонацион-мелодик яңгырашы. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 17,18 | Тыныш билгеләре. | 2 |
| 19 | Проза әсәрләрен сәнгатьле уку күнегүләре. | 1 |
| 20 | Шигъри әсәрләрне сәнгатьле уку. | 1 |
| 21 | Әдәби кичә. | 1 |
| 22 | Драма әсәрләренең үзенчәлекләре. | 1 |
| 23 | К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры. Артистлар белән очрашу кичәсе. | 1 |
| 24 | Т.Миңнуллинның “Кайда хаклык, кайда дөреслек?” комедиясе. Әсәрнең идеясе, күтәрелгән проблемаларны ачыклау, образларга сыйфатлама бирү. | 1 |
| 25, 26, 27 | Т.Миңнуллинның “Кайда хаклык, кайда дөреслек?” комедиясе.<br>1. Текст белән эш.<br>2. Пьесаны, рольләргә бүлеп, сәнгатьле уку күнегүләре. | 3 |
| 28 | Сәхнәдә хәрәкәтләнү, үз-үзеңне тоту, мимика, жестлар. | 1 |
| 29, 30,31,32 | Т.Миңнуллинның “Кайда хаклык, кайда дөреслек?” комедиясен сәхнәдә уйнау. | 4 |
| 33 | Т.Миңнуллинның “Кайда хаклык, кайда дөреслек?” комедиясен тамашачыларга күрсәтү. | 1 |
| 34 | Куелган спектакльгә анализ. | 1 |

## Программаның эчтәлеге

| № | Уку материалының темасы һәм эчтәлеге | Үткәрү формасы |
|---|---|---|
| 1 | Кереш шөгыль. Сөйләмдә уңышларым һәм җитешсезлекләрем.<br>1. Һәр укучы риториканың нинди өлкәсендә осталыкка ирешүе, уңышсызлыклары һәм теләкләре турында сөйли.<br>2. Ораторлык сәнгатенең тормышта әһәмияте турында нәтиҗә ясау (тыңлаганда, телдән һәм язма сөйләмдә, укуда).<br>3. Тест. “Синең холкың”. Сөйләүче холкының тыңлаучыга тәэсире.<br>4. Риторикада уңышларга ирешүнең юлларын билгеләү. | Әңгәмә, тест. |
| 2 | Аралашу кагыйдәләре.<br>1. Коммуникатив хаталар. Төрле | Әңгәмә, эшлекле уен |

| | | |
|---|---|---|
| | ситуацияләрне анализлау, аралашуны кыенлаштыручы сәбәпләрне күрсәтү.<br>2. Ситуацияләрдә очраган хаталарны төзәтүгә күнегүләр. Рольле уен.<br>3. Телефоннан сөйләшү тәртибе. Төрле ситуацияләргә бәйле уеннар уйнау.<br>4. Хат, тәбрикнәмә язу. | |
| 3 | Татар сүз сәнгатенең күренекле вәкилләре.<br>1. Укучыларның проект эшләре.<br>2. Артистлар уеннары үрнәкләрен тыңлау һәм карау. | Укучыларның проект эшләре буенча чыгышлары. Видео, аудиоязмалар карау һәм тыңлау. |
| 4 | Г. Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театры. | Театрга экскурсия, спектакль карау. |
| 5 | Хәрәкәтләр, мимика, һәм гәүдә тотышы нәрсәләр турында сөйли?<br>1. Кешенең хәрәкәтләре, мимикасы, гәүдәсен тотышы. Рәсем сәнгате һәм сынлы сәнгать әсәрләрен күзәтү. | Күргәзмәгә экскурсия, әңгәмә |
| 6 | Чыгыш ясаганда, аралашканда кешенең гәүдәсен тотышы һәм мимикасының роле.<br>1. Мимика, хәрәкәтләр белән музыка астында төрле хис-кичерешләрне тасвирлап күрсәтүгә күнегүләр.<br>2. Текстлардан өзекләр уку. | Әңгәмә, күнегүләр |
| 7 | Хис-кичерешләрне белдерү.<br>1. Күтәренке рухлы текстлар уку.<br>2. Күңелле, кызык хәлләрне тасвирлау.<br>3. Ямансу, күңел тетрәткеч вакыйгаларны чагылдыру. | Аудиоязалар тыңлау, әңгәмә, уку күнегүләре. |
| 8 | Сулыш күнегүләре.<br>1. Иснәү күнегүләре.<br>2. Диафрагма, кабырга ара һәм эчнең аскы мускулларын ныгыту күнегүләре. | Күнегүләр ясау |
| 9 | Сөйләм һәм яңгырау аппаратын күнектерү.<br>1. Артикуляция һәм яңгырау аппаратына гимнастика күнегүләре. | Күнегүләр ясау |
| 10 | Сузык авазлар орфоэпиясе.<br>1. Сузык авазларны дөрес әйтүгә | Күнегүләр ясау |

| | | |
|---|---|---|
| | күнегүләр.<br>2. Тизәйткечләр өйрәнү.<br>3. Текстлардан өзекләр укыту. | |
| 11 | Тартык авазлар орфоэпиясе.<br>1. Тартык авазларны дөрес әйтүгә күнегүләр.<br>2. Тизәйткечләр өйрәнү.<br>3. Дикцион тренинг. | Күнегүләр ясау |
| 12 | Басым һәм аның төрләре.<br>1. Сүзне оештыручы иҗек басымы, урыны, басым алмый торган кушымчалар.<br>2. Төрле сүз төркемнәренә басымны дөрес куя белү күнегүләре эшләтү.<br>3. Тест эшләтү. | Лекция, күнегүләр, тест |
| 13 | Басым һәм аның төрләре.<br>1. Логик басым кагыйдәләре. Фразадагы әһәмиятле сүзләрне билгеләүгә ярдәм итүче кагыйдәләр һәм бәйләнешләрне күрсәтү.<br>2. Мәгънәви басым.<br>3. Текстлардан өзекләр укыту. | Лекция, күнегүләр |
| 14 | Мәгънәви паузалар.<br>1. Тиешсез урында ясалган паузаларның мәгънәне бозулары турында нәтиҗә ясау.<br>2. Мәгънәви паузалар белән таныштыру:<br>- психологик пауза;<br>- киеренкелек тудыручы пауза;<br>- әйтми калу паузасы;<br>- физиологик пауза;<br>- ритмик пауза.<br>3. Әдәби әсәрләрдән, паузаларны дөрес куеп, өзекләр уку күнегүләре эшләү. | Уку күнегүләре, аудиоязмалар тыңлау |
| 15 | Сөйләм тизлеге.<br>1. Сөйләм тизлегенә йогынты ясаучы күренешләрне анализлау.<br>2. Такмаклар, санамышлар әйтү.<br>3. И.Юзеев, Х.Туфан шигырьләрен сәнгатьле уку күнегүләре. | Әңгәмә, практик эш |
| 16 | Сөйләмнең интонацион-мелодик яңгырашы.<br>1. Сөйләм агышында тавыш тоны үзгәрешенең типик очраклары белән таныштыру. | Лекция, күнегүләр |

| | | |
|---|---|---|
| | 2. Шигъри әсәрләрне интонация белән уку күнегүләре. | |
| 17 | Тыныш билгеләре.<br>1. Тыныш билгеләренең яңгыраудагы төп вазыйфалары.<br>2. Тыныш билгеләренә игътибар итеп укырга күнектерү. | Әңгәмә, күнегүләр |
| 18 | Тыныш билгеләре.<br>1. Тыныш билгеләренә игътибар итеп укырга күнектерү.<br>2. Иҗади эш. Һәр тыныш билгесенә туры килерлек җөмләләр төзү. | Күнегүләр, иҗади эш |
| 19 | Проза әсәрләрен сәнгатьле уку күнегүләре.<br>1. Текст белән эш. Ә.Еники хикәяләрен анализлау, сәнгатьле укырга өйрәнү:<br>- текстның эчке мәгънәсен ачыклау;<br>- сөйләм тактлары;<br>- мәгънәви басым;<br>- мәгънәви паузалар;<br>- мәгънәви перспектива;<br>- сөйләм тизлеге. | Әңгәмә, практик эш |
| 20 | Шигъри әсәрләрне сәнгатьле уку.<br>1. Шигырьдә ритм.<br>2. Рифма төрләре.<br>3. Шигырьдә ритм төзелешен саклау кагыйдәләре.<br>4. А.Арсланов, И.Әхмәтҗанов башкаруында аудиоязмалар тыңлату.<br>5. Силлабик шигырь һәм гарузны уку үзенчәлекләре. Г.Тукай шигырьләрен сәнгатьле уку. | Лекция, күнегүләр, аудиоязмалар тыңлау |
| 21 | Әдәби кичә. | Күнекмәләрне тикшерү |
| 22 | Драма әсәрләренең үзенчәлекләре.<br>1. Драма әсәрләренең төрләре - комедия, драма, трагедия турында белемнәрен искә төшерү.<br>2. Драма әсәрләреннән өзекләр карау.<br>3. Диалог һәм полилогларны сәнгатьле уку күнегүләре. | Әңгәмә, практик эш |
| 23 | К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры. Артистлар белән очрашу кичәсе. | Очрашу кичәсе |
| 24 | Т.Миңнуллинның “Кайда хаклык, кайда | Практик шөгыль |

| | | |
|---|---|---|
| | дөреслек?” комедиясен укып танышу, идеясен, күтәрелгән проблемаларны ачыклау, образларга сыйфатлама бирү. | |
| 25, 26, 27 | Текст белән эш. Пьесаны рольләргә бүлеп сәнгатьле уку күнегүләре. | Практик шөгыль |
| 28 | Сәхнәдә хәрәкәтләнү, үз-үзеңне тоту, мимика, жестлар. | Практик шөгыль |
| 29 - 32 | Т.Миңнуллинның “Кайда хаклык, кайда дөреслек?” комедиясен сәхнәдә уйнау. | Практик шөгыль |
| 33,34 | Т.Миңнуллинның “Кайда хаклык, кайда дөреслек?” комедиясен тамашачыларга күрсәтү. | Күнекмәләрне тикшерү |
| 35 | Куелган спектакльгә анализ. | Уенга бәя бирү |

**Укытучы өчен әдәбият.**

1. Хаков В.Х.Татар милли әдәби теле формалашу чорында драма әсәрләренең теле//Татар тел белеме мәсьәләләре. – Кит. 3 – Казан, 1969
2. С.Ш.Поварисов. Тел – күңелең көзгесе. Казан Татарстан китап нәшрияты, 1982
3. М.И.Чистякова. Психогимнастика. – Москва: Просвещение, 1990
4. Нуриев Г.-Р. С. Татар сәхнә сөйләме: Монография. – Казан: Татар “Мирас” кит. нәшр., 1998
5. Нуриев Г.-Р. С. Сәнгатьле уку. Методик ярдәмлек. – Казан: 2000
6. Нуриев Г.-Р. С., Хәйруллина А.Х. Сәхнә теле. – Казан: “Отечество” нәшр., 2004